ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16 гыйнвар 2020ел № 79

Башкарма комитетның «Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү турында» 2017 елның 23 ноябрендәге 7238 номерлы карарының 1 нче кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында

«Тәмәкесез никотинлы продукцияне, никотин кертү электрон системаларын балигъ булмаганнарга сатуны тыю турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 25 декабрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү турында» 2017 елның 23 ноябрендәге 7238 номерлы карарының (Башкарма комитетның 2017 елның 22 декабрендәге 8056 номерлы, 2018 елның 30 мартындагы 1696 номерлы карарлары редакциясендә) 1 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемдә «2.14» цифрыннан соң «2.16» цифрын өстәргә;

2) 3 пунктта «2.14» цифрыннан соң «2.16» цифрын өстәргә;

3) 6 пунктта «2.4-2.7» цифрларыннан соң «2.16» цифрын өстәргә;

4) 7 пунктта «2.14» цифрыннан соң «2.16» цифрын өстәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтовага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев